# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Конституциясенең
<u>108 статьясына үзгәрешләр кертү турында</u>

Татарстан Республикасы Конституциясенең 108 статьясына (Татарстан Республикасы Югары Советы Җыелма басмасы, N9-10, 1992: N 11, 1994; Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Җыелма басмасы, N2-3, N 12, 1995) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 108 статьяның беренче бүлегендә "алтмыш биш яшьтән өлкәнрәк булмаган" дигән сүзләрне, шулай ук соңгы җөмләне төшереп калдырырга.

2. 108 статьяның икенче бүлегендә "Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар саны чикләнми" дигән җөмләне "Татарстан Республикасы Президентын сайлау альтернатив нигездә үткәрелә" дигән җөмләгә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 27 ноябре
N 881